**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

---

РАСПОРЯЖЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

______________　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　№ __________

«Экстремизмга - Юк!» айлыгын үткәрү турында

Милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту, террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремистлык чагылышларына халыкның түзеп тормавы атмосферасын булдыруга юнәлтелгән иҗтимагый фикер формалаштыру максатларында, **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә 2022 елның 01 сентябреннән 30 сентябренә кадәр «Экстремизмга - Юк!» айлыгын уздырырга.
2. «Экстремизмга - Юк!» айлыгын үткәрү буенча беркетелгән чаралар планын (алга таба - план) расларга.
3. Планда каралган чараларны үтәү өчен җаваплы Башкарма комитетның, оешмаларның һәм учреждениеләрнең бүлек җитәкчеләренә 2022 елның 31 августына кадәр план чараларын үткәрүгә әзерлекне оештырырга, шулай ук билгеләнгән срокларда аны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.
4. Җәмәгать һәм дини берләшмәләргә, яшьләр һәм башка оешмаларга план чараларын гамәлгә ашыруда актив катнашуны тәкъдим итәргә.
5. Авыл җирлекләре башлыкларына тиешле авыл җирлекләре территориясендә айлык үткәрү планнарын расларга тәкъдим итәргә.
6. “Татмедиа” АҖ филиалына “Экстремизмга - Юк!” айлыгы чараларын массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртуны тәэмин итәргә.
7. Әлеге боерыкны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның эшләр идарәчесе Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Л.Р.Зарипов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты боерыгына
___________________ 2022 ел,
кушымта

«Экстремизмга - Юк!» айлыгын үткәрү чаралары планы

| № т/б | Чаралар | Үтәү вакыты | Җаваплы башкаручылар* |
|---|---|---|---|
| 1 | Районның гомуми белем бирү оешмаларында «Экстремизмга - Юк!» темасына бердәм дәрес | 2022 елның 03 сентябре | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МКУ |
| 2 | Район мәчетләрендә террорчылыклык актлары корбаннары истәлегенә багышланган җомга вәгазе | 2022 елның 03 сентябре | ТР мөселманнары рухи идарәсенең Актаныш Мөhтәсибәте |
| 3 | Район мәктәпләрендә сыйныф сәгатьләре үткәрү:<br>- милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрдә толерантлыкны үстерүгә юнәлтелгән шөгыльләр;<br>- террорчылык актлары турында ялган хәбәрләрне профилактикалау буенча дәресләр;<br>- гадәттән тыш хәл барлыкка килгәндә, мәктәпкәчә учреждениеләрдә укучыларны һәм тәрбияләнүчеләрне эвакуацияләү буенча практик дәресләр | айлык үткәрү чорында | Актаныш муниципаль районының “Мәгариф идарәсе” МКУ (килешү буенча), Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге, “Федераль янгынга каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча 15 отряды” ФДКУ |
| 4 | "Экстремизмга - Юк!" тематик кинокүрсәтүләр | айлык үткәрү чорында | социаль һәм агарту бүлеге, «Яшьлек» милли-мәдәни үзәге |
| 5 | «Экстремизмга - Юк!», «Террорчылыкка каршы җәмгыять» һәм башка темалар буенча террорчылыкка каршы китап күргәзмәсе. | Айлык үткәрү чорында | «Актаныш авылара үзәк китапханәсе» МБУ |
| 6 | «Терроризм, экстремизм - кешелеккә каршы явызлык» темасына радиотапшырулар | Айлык үткәрү чорында | «Татмедиа» ААҖ филиалы - Актаныш ИРЦ |
| 7 | Район торак пунктларында барлык милләтләр катнашында төрле спорт һәм мәдәни чаралар үткәрү | айлык үткәрү чорында | Авыл җирлекләре башлыклары, социаль һәм агарту эшләре бүлеге, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 8 | Район мәгариф учреждениеләре укучылары арасында «Спорт экстремизмга каршы!» шигаре астында төрле спорт уеннары һәм ярышлары | айлык үткәрү чорында | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” МКУ; Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | үткәрү | | яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге; авыл җирлекләре башлыклары |
| 9 | Террорчылык актлары куркынычы барлыкка килгән һәм шикле предметларны ачыклау очракларында гамәлләрне аңлату акценты белән мәдәният, мәгариф, спорт учреждениеләрендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча вазыйфаи затларны һәм хезмәткәрләрнең семинар-укуы | Айлык үткәрү чорында | Актаныш муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия, социаль һәм агарту эшләре бүлеге, «Мәгариф идарәсе» МКУ, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге, авыл җирлекләре башлыклары |
| 10 | Без халыклар дуслыгы өчен! Без көч куллануга каршы!» рәсем конкурсы | айлык үткәрү чорында | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МКУ |
| 11 | Яшьләр арасында экстремистик идеяләр һәм кәеф дәрәҗәсен ачыклау максатында белем бирү оешмалары укучылары арасында анкета уздыру | айлык үткәрү чорында | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының социаль һәм агарту бүлеге; Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 12 | Айлык чараларын яктырту һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтү | айлык үткәрү чорында | «Татмедиа» ААҖ филиалы - Актаныш ИРЦ |
| 13 | План чараларын үтәү турында Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссия аппаратына хисап | 2022 елның 10 октябренә кадәр | Актаныш муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссиясе. |

**җаваплы башкаручылар, турыдан-туры Башкарма комитет җитәкчесенә буйсынмаган башкаручылар килешү буенча билгеләнә.